# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче Максим Пүчинкәсе авылында 2021 елга үзара салым кертү турында

№ 8 11.11. 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Максим Пүчинкәсе авылында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Максим Пүчинкәсе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400(дүрт йөз) сумкүләмендәүзарасалымкертергә.

2. Җыелганакчаларныҗирлеәһәмияттәгемәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Максим Пүчинкәсе авылы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;

-Максим Пүчинкәсе авылында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру.

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А. Гиззатуллина